РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 17 декабре Кукмара ш. № 96

Кукмара муниципаль район Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, индикатив күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль район Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, индикатив күрсәткечләрен яңа редакциядә бәян итәргә (кушып бирлә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

Кукмара муниципаль район Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 91 номерлы карары (2021 елның 17 декабрендәге 96 номерлы карары редакциясендә) белән расланган

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өчен контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре, индикатив күрсәткечләр.**

**1. Төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан әһәмияте:**

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше – 70 %.

Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү өлеше – 100 %.

Контроль органының һәм (яки) аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) нигезле шикаятьләр өлеше – 0 %.

Контроль чараларның юкка чыгарылган нәтиҗәләре өлеше – 0 %.

нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланган, әмма тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән контроль чараларның өлеше – 5%.

Контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында чыгарылган суд карарларының өлеше – 95 %.

**2. Индикатив күрсәткечләр**

1) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуын ачыклау нигезендәхисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү (күзәтчелек) чаралары саны, хисап чоры өчен;

3) хисап чорында үзара хезмәттәшлек белән үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

4) хисап чорында үзара хезмәттәшлек белән үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чарасының һәр төре буенча контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

7) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

8) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

9) хисап чорында нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

11) контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны, хисап чоры өчен;

12) контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән, прокуратура органнары килештерүдән баш тарткан гаризалар саны, хисап чоры өчен;

13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

14) куркыныч категорияләренә кертелгән, һәр куркыныч категориясе буенча хисап чоры ахырына исәпкә алынган объектларының саны;

15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы исәпкә алынган затларның саны;

16) хисап чорында аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы исәпкә алынган затларның саны;

17) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карап тикшерү вакыты бозылган шикаятьләрнең саны;

18) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү турында контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү турында контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән, аларга карата бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

20) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны.